# КАРАР
## Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
## Үчәлле авыл җирлеге Советы

Үчәлле авылы № 143 17 май, 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хокукый актлар, шул исәптән норматив характердагы муниципаль хокукый актлар реестрларын оештыру һәм алып бару тәртибе турында 2017 елның 13 ноябрендәге 77 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында”

Кадрлар үзгәрешләре белән бәйле рәвештә

Үчәлле авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хокукый актлар, шул исәптән норматив характердагы муниципаль хокукый актлар реестрларын оештыру һәм алып бару тәртибе турында " 2017 елның 13 ноябрендәге 77 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хокукый актлар, шул исәптән норматив характердагы муниципаль хокукый актлар реестрларын алып баруга вәкаләтле булып, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре Кадырова Филиза Гыйльмегаян кызын килештереп билгеләргә.»;

2. Әлеге карар 2018 елның 3 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru. һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http//aznakayevo.tatar.ru.веб-адрес буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Г.М.Төхвәтуллина